МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.12.2015 г.Казань № 17-254

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының ведомство бүләген гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре хезмәткәрләрен, шулай ук тармак үсешенә актив ярдәм итүче затларны бүләкләү максатларында боерык бирәм:

1. «ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе» ведомство бүләген гамәлгә куярга.
2. «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе» ведомство бүләге турында нигезләмә (кушымта итеп бирелә) расларга.
3. Бүләкләү өчен материаллар әзерләү эшен оештыруны, ведомство бүләкләрен исәпкә алуны һәм тапшыруны кадрлар бүлегенә йөкләргә.
4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә, икътисадый үсеш һәм индикатив идарә бүлегенә бүләк продукциясе әзерләүне һәм әзерләү белән бәйле чыгымнарны түләүне тәэмин итәргә, бүләкләү продукциясен исәпкә алу һәм исәптән төшерүне алып барырга.
5. Хокукый тәэмин итү секторына әлеге боерыкны кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.А.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрлыгының 2015
елның 18 декабрендәге П-254
номерлы
боерыгы белән расланды

**«Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе турында нигезләмә**

1. «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе (алга таба – бүләк билгесе) белән милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан, мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы оешмалары хезмәткәрләре, шулай ук тармак үсешенә актив ярдәм итүче затлар бүләкләнә, түбәндәгеләр өчен:

тармак үсешендәге казанышлар;

тармак эшенең нәтиҗәлелеген арттыруга, эшне оештыруны камилләштерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеге үсеше темпларын тизләтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга зур өлеш кертү;

яңа техника һәм технологияләр эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә актив катнашу;

нәтиҗәле фәнни, уйлап табу һәм рационализаторлык эшен алып бару һәм тармак өчен белгечләр һәм квалификацияле кадрлар әзерләү өлкәсендәге казанышлар;

хезмәтне саклау шартларын, куркынычсызлык техникасын яхшырту һәм элемтә чараларының авариясез эшен тәэмин итү;

тармак эшчәнлеген җайга сала торган хокукый актларны эшләүдә һәм камилләштерүдә катнашу.

2. Тармак оешмалары хезмәткәрләре күкрәк билгесе белән җитәкченең Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры (алга таба – Министр) исеменә үтенечнамәсе нигезендә бүләкләнәләр.

3. Күкрәк билгесе белән бүләкләү турындагы материаллар Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының бүләкләү материалларын карау комиссиясе утырышында карала.

4. Күкрәк билгесе белән бүләкләү Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы боерыгы нигезендә башкарыла.

5. Күкрәк билгесе Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы коллегиясе утырышларында яки оешма эшчәнлегенә багышланган тантаналы чараларда (һөнәри бәйрәмнәрдә, юбилей даталарында) тапшырыла.

6. Күкрәк билгесен Министр тапшыра. Аерым очракларда, Министр йөкләмәсе буенча һәм аның исеменнән бүләкләү билгесен аның урынбасарлары тапшырырга хокуклы.

7. Күкрәк билгесенә таныклык бирелә. Күкрәк билгесе дубликаты һәм күкрәк билгесенә таныклык дубликаты бирелми. Күкрәк билгесе белән кабат бүләкләү күздә тотылмый.

## «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесенә тасвирлама

Күкрәк билгесе 20 мм диаметрлы алтын төстәге түгәрәк формада. Күкрәк билгесе алтын белән сиптереп капланган латуньнан эшләнгән. Үзәктә Татарстан Республикасы флагы фонында зәркән эмале белән эшләнгән микросхемалар пайкасы сурәтләнгән. «ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» язуы тугым буенча лазер белән шомартып теркәлгән.

Күкрәк билгесенең икенче ягында кием-салымга беркетү җайланмасы бар.

Күкрәк билгесе күкрәкнең сул ягында йөри һәм, дәүләт бүләкләре булганда, алардан соң урнаштырыла.

## «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе таныклыгына тасвирлама

160га 100 мм үлчәмендәге күкрәк билгесенә таныклык тышлыгы чия төсендәге тышлык материалыннан ясала. Таныклыкның алгы ягында үзәк өлешендә алтын төсле буяу белән «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе ТАНЫКЛЫГЫ дигән язу урнаштырыла.

Таныклыкның эчке сул ягында күкрәк билгесе сурәте урнаштырыла;

Билге астында буш юл, уртада «N» язуы, анда таныклыкның теркәү номеры күрсәтелә;

Таныклыкның эчке уң ягында өске якта «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә» дигән язу урнаштырыла.

Астарак – өч буш юл, беренче юл астында – «фамилия» язуы, икенче юл астында – «исем» язуы, өченче юл астында – «ата исеме» язуы.

Үзәк өлештә «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» язуы урнаша.

Сул якта аскы өлештә – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры» һәм ФИА, уң якта – имза урыны.

Аскарак – ике буш юл, беренчесенең урта өлешендә – «N» язуы, анда бүләкләү турындагы боерык номеры күрсәтелә, икенче юлда — боерыкны имзалау датасы.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2015 елның
_______________ № _________
боерыгы белән расланды

**«Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе турында нигезләмә**

1. «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе (алга таба – бүләк билгесе) белән милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан, мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы оешмалары хезмәткәрләре, шулай ук тармак үсешенә актив ярдәм итүче затлар бүләкләнә, түбәндәгеләр өчен:

тармак үсешендәге казанышлар;

тармак эшенең нәтиҗәлелеген арттыруга, эшне оештыруны камилләштерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеге үсеше темпларын тизләтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга зур өлеш кертү;

яңа техника һәм технологияләр эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә актив катнашу;

нәтиҗәле фәнни, уйлап табу һәм рационализаторлык эшен алып бару һәм тармак өчен белгечләр һәм квалификацияле кадрлар әзерләү өлкәсендәге казанышлар;

хезмәтне саклау шартларын, куркынычсызлык техникасын яхшырту һәм элемтә чараларының авариясез эшен тәэмин итү;

тармак эшчәнлеген җайга сала торган хокукый актларны эшләүдә һәм камилләштерүдә катнашу.

2. Тармак оешмалары хезмәткәрләре күкрәк билгесе белән җитәкче үтенече буенча бүләкләнәләр.

3. Күкрәк билгесе белән бүләкләү турындагы материаллар Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының бүләкләү материалларын карау комиссиясе утырышында карала.

4. Күкрәк билгесе белән бүләкләү Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы боерыгы белән башкарыла.

5. Күкрәк билгесе Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы коллегиясе утырышларында яки оешма эшчәнлегенә багышланган тантаналы чараларда (һөнәри бәйрәмнәрдә, юбилей даталарында) тапшырыла.

6. Күкрәк билгесен Министр тапшыра. Аерым очракларда, Министр йөкләмәсе буенча һәм аның исеменнән бүләкләү билгесен аның урынбасарлары тапшырырга хокуклы.

«Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесенә тасвирлама

Күкрәк билгесе 20 мм диаметрлы алтын төстәге түгәрәк формада. Күкрәк билгесе алтын белән сиптереп капланган латуньнан эшләнгән. Үзәктә Татарстан Республикасы флагы фонында зәркән эмале белән эшләнгән микросхемалар пайкасы сурәтләнгән. «ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» язуы тугым буенча лазер белән шомартып теркәлгән.

Күкрәк билгесенең икенче ягында кием-салымга беркетү җайланмасы бар.

Күкрәк билгесе күкрәкнең сул ягында йөри һәм, дәүләт бүләкләре булганда, алардан соң урнаштырыла.

Күкрәк билгесенә таныклык бирелә.

«Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе таныклыгына тасвирлама

160га 100 мм үлчәмендәге күкрәк билгесенә таныклык тышлыгы чия төсендәге тышлык материалыннан ясала. Таныклыкның алгы ягында үзәк өлешендә алтын төсле буяу белән «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе ТАНЫКЛЫГЫ дигән язу урнаштырыла.

Таныклыкның эчке сул ягында күкрәк билгесе сурәте урнаштырыла;

Билге астында буш юл, уртада «N» язуы, анда таныклыкның теркәү номеры күрсәтелә;

Таныклыкның эчке уң ягында өске якта «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә» дигән язу урнаштырыла.

Астарак – өч буш юл, беренче юл астында – «фамилия» язуы, икенче юл астында – «исем» язуы, өченче юл астында – «ата исеме» язуы.

Үзәк өлештә «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендәге казанышлар өчен» язуы урнаша.

Сул якта аскы өлештә – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры» һәм ФИА, уң якта – имза урыны.

Аскарак – ике буш юл, беренчесенең урта өлешендә – «N» язуы, анда бүләкләү турындагы боерык номеры күрсәтелә, икенче юлда — боерыкны имзалау датасы.

---